
**/Чал тарихта эзле без!/**

## *Туган ягыбызның борынгы тарихы*




Безнең Түбән Майна авылы җирләрендә халык таш гасырларда ук яшәгән. Моңа Иске авыл урыныннан табылган таш балта һәм кыргычлар дәлил булып тора.

Безнең эрага кадәр 1600-1200 нче елларда безнең төбәктә **«Бура»** культурасына караган кабиләләр яшәгән. Алардан калган авыл урыннары Карамалы табыр ягында, Чурмак ерганагы тамагыннан төньяктагы калкулыкта, тирән чокыр посадкасы янындагы кырда һәм Мунчала күле буенда табылды. «Буралылар» дип аталу ул халыкка мәет күму йолаларыннан күчкән. Алар мәетләрен кабер эченә кечкенә буралар бурап күмә торган булганнар. Алар утрак тормышлы булсалар да, игенчелек белән шөгыльләнмәгәннәр, мал асрап көн күргәннәр.

400-700 нче еллар тирәсендә безнең җирлектә **«Имән Кискә»** культурасына караган халык гомер иткән. Аларның торулыклары Чирмешәннең уң ягында – буа турысындагы кырның аскы өлешендә һәм Иске авыл җирендә булган. «Имәнкискәлеләр» безнең төбәктә беренче җир эшкәртеп иген үстерүчеләр булганнар һәм утрак тормыш белән яшәгәннәр. Аларда, шулай ук, тимерчелек һөнәре нык алга киткән булган.

Туган ягыбыздагы тарихи истәлекле урыннарның күпчелеге VIII-XIII гасырларга – **Болгар дәүләте** чорына карый. Бу дәвер башында безнең якларда болгар кабиләләренә кадәрге җирле халык яшәгән. Аларның торулыклары хәзерге авылның көнбатыш ягында һәм Чиялектәге кала эчендә булганлыгы ачыкланды.

922-1236 нчы еллар арасында туган ягыбыз Болгар иленең башкаласы – данлыклы **Биләр** шәһәренең якын тирәлеген тәшкил иткән. XI гасырда Болгар куаклыгының көньягында, Мунчала күле буенда, Нәмәт һәм Мәхсет елгалары арасындагы кырда яңа авыллар барлыкка килә. Ул чорда Чиялектәге калада һәм хәзерге авыл урынында да тормыш гөрләп барган. Мәктәп урынында, авылның көнбатыш өлешендәге бакчаларда, зиратның көньяк читендә XI-XIII гасырларга караган табылдыкларны еш очратырга мөмкин.

1236-1242 нче еллардагы монгол яуларыннан соң да безнең җирлектә тормыш дәвам итә. Чиялектәге калада һәм аның бистәсе булырга тиешле Тукморза буендагы авылда халык 1300 нче елларга чаклы яшәгән. **Алтын Урда** дәүләтенең чәчәк аткан дәверендә – XIV гасырның беренче яртысында, яңа авыллар да барлыкка килә. Шундыйлардан Зур чирәм һәм техника паркы урынындагы һәм Майна елгасы тамагындагы авылларны атарга мөмкин. 1350 нче еллар ахырына бу авыллар яшәүдән туктый. Шуннан соң, 1360 нчы елларда Иске авылга нигез салына.

***Рафик Насыйров, тарих укытучысы, тарих фәннәре кандидаты***

**/Котлыйбыз!/**



Ноябрь аенда дөньяга килгән дусларыбыз **Нурматова Асияне** (IV сыйныф), **Хәйруллин Айназны** (IX сыйныф) һәм **Гафиятуллин Саматны** (X сыйныф) туган көннәре белән котлап, ныклы сәламәтлек, укуларында зур уңышларга ирешүләрен телибез.


**Газетаны гамәлгә куючы – Түбән Майна урта мәктәбе**
**Мөхәррир – Фәнүзә Гафиятуллина**
**Редколлегия әгъзалары: Зәйнәп Нурматова, Самат Гафиятуллин, Кәүсәр Насыйрова, Ләйсән Закирова, Мәдинә Әхсәнова, Камил Төхвәтуллин**



# Мәктәп хәбәрчесе

**Түбән Майна урта мәктәбе газите**

**№9 (№50) ноябрь 2023 ел**



**Тел. 8 (84344) 4-38-46** sch1644maina@mail.ru


**/Мөхәррир минбәре/**

## *Тел склерозы дәваланамы?*



80нче еллар ТАТАР МАТБУГАТЫ

КӘГАЗЬ САРГАЯ - СҮЗ ИСКЕРМИ

ТИ TATAR-INFORM.TATAR

ӘЛЕ ТАГЫН БЕР АВЫРУ БАР. АНЫСЫ ТАТАР БАЛАЛАРЫНА ГЫНА КАГЫЛА. МЕДИЦИНА ТЕРМИНЫ БЕЛӘНРӘК ӘЙТСӘК, АНЫ ТЕЛ СКЛЕРОЗЫ ДИЯРГӘ БУЛЫР ИДЕ. АНЫҢ ДИАГНОЗЫН СЕЗ ЯХШЫ БЕЛӘСЕЗ: БАЛА ТУГАН ТЕЛЕН ОНЫТА. ШУНЫҢ НӘТИҖӘСЕ БУЛАРАК, АКРЫНЛАП ТУГАН ХАЛКЫНЫҢ КУЛЬТУРАСЫН, ТАРИХЫН, ӘДӘБИЯТЫН ХӘТЕРЕННӘН ҖУЯ БАШЛЫЙ.
ӘТИ-ӘНИСЕНӘ, ТУГАН ҖИРЕНӘ, ТУГАН ИЛЕНӘ БУЛГАН МӨНӘСӘБӘТЕ ҮЗГӘРӘ. ГУМАНИЗМ, ПАТРИОТИЗМ, ФИДАКЯРЛЕК ҺӘМ ӘХЛАК СЫЙФАТЛАРЫ ЮГАЛА. БУ АВЫРУ БЕЛӘН КҮПМЕ ТАТАР БАЛАСЫ АВЫРЫЙДЫР, ӘЙТӘ АЛМЫЙМ. ӘММА АЛАР КҮП, БИК КҮП.

Роберт абый Миңнуллинның бу сүзләре беркайчан да искермәс кебек. Ана телебезне үстерү турында ничә еллардан бирле сөйләнсәк тә, нәтиҗәле эшли белмибез, күрәмсең.

Минемчә, тел склерозы белән беренче чиратта балалар түгел, ә өлкәннәр авырый. Ә алардан инде чир баласына да күчә. Оныгына да! Әгәр Татарстанда беренче тел булып татар теле, ә икенче урыс теле торса, җитәкчеләр ике телне белергә тиеш булсалар, югары уку йортларында татар телендә уку мөмкинлеге булса, әти-әни өйдә чиста татар телендә сөйләшеп, баласын татар бакчасына биреп татар мәктәбендә укытмас идеме???

Туганнарыбыз арасында да бу авыр мәсьәлә көннән-көн авырлаша гына бара. Балалары татар телендә бер сүз дә белмәгәннән туган соравыма: “аларның киләчәген уйлап, югары уку йортында тел киртәсе булмасын өчен, бакчага киткәч тиз аралаша башлый алсын өчен, телен урысча ачтырабыз, урыс мәктәбенә бирәбез. Хәзер мәктәп программасы да әнә нинди...! Әле ЕГЭ бирәселәре дә бар бит”– диләр. Менә шуннан соң аларга туган телнең дәрәҗәсен аңлатып кара!

Үзебезнең чын татар авылы балалары, татар мәктәбен тәмамлап, имтиханнарны рус телендә тапшыра алганын да, югары уку йортларына керерлек баллар җыйганын да дәлилләп карыйм. Бер генә авыл баласының да эшсез, белемсез аптырап йөргәнен әлегә белмибез бит. Һәрберсе үз юлын тапкан, уңышлы эшли торган укучыларыбыз бар безнең. Югары, дәрәҗәле урыннарда эшләүче түрәләр дә элеккеге авыл балалары бит. Алар фикеренчә, мәктәпкә кергәнче бала „профессор" булырга тиеш. Русча яхшы белгәч, барлык киртәләрне дә җиңел үтеп, киләчәктә ул “зур” кеше булачак. Менә шулайрак фикер йөрткән әти-әниләрнең шактый булуы җанны кисә. Алар олыгайган көннәрендә туган теленә кайтасын, калебенең үз телен сораячагын аңламый. Газиз телләре исләренә төшәр, әби-бабайларга әйләнгәч, балаларының йөрәккә якын туган телдә эндәшүләрен күңелләре белән көтә башларлар. Бала, онык телдән читләшкән, өйдә әти-әни туган телдә аралашмый икән, мондый фаҗигагә кем гаепле соң?

Икътисади мәнфәгатьләрне кайгыртып йөри-йөри, күңелебезне, рухи хәләтебезне, иманыбызны онытмасак, милләтебез язмышына битараф булмасак иде. Туган телен белгән бала, башка телне дә җиңел үзләштерәчәк, ул кайда да югалмас иде. Үз теленә ихтирамны тойса гына кеше башка телгә дә ихтирам белән караячак ул. Ата-анасы чит иткәч, балада ана сөте белән кергән телне якын итү кайдан килсен икән? Мәктәп кенә аны ничек итеп җәлеп итә алсын?

Башка алдынгы милләтләр арасында лаеклы урын тоткан, үз теленә, иманына, мәдәниятенә тугрылыклы халык булып кала алсак иде. Гомәр ага Бәшировның “ Тел халыкның акылын, гореф-гадәтен, дөньяга карашын, фәлсәфәсен, тарихын, кыскасы, бөтен күңел байлыгын, мең еллар буена үзенә сеңдереп килеп, безнең заманнарга җиткергән чиксез кадерле хәзинә” дип әйткән сүзләрен югарыда руслашу ягын өстенрәк күргән әти-әниләргә җиткерәсем килә. Шуны аңласалар, тел склерозы авыруын, бәлки, дәвалап булыр иде.

***Фәнүзә Гафиятуллина, баш мөхәррир***




Әни, димен иртән үк
Әни, димен кичтән дә
Әни дигән иң җылы сүз
Язылган шул йөрәккә.

Әниләрсез чәйләр салкын,
Өй түрләре күңелсез.
Әни өйдә булган чакта
Бигрәк рәхәт, беләсез?

Әниле булуның рәхәте
Елмайта бит йөрәкне
Һәр сабыйга булсын иде
Аналар мәхәббәте.

Әни җылысы һәркемгә
Булсын иде озаклап
Шуңа күрә әниләрне
Торыйк әле без саклап.

Шатландырыйк яхшы укып
Сөендерик әдәп белән.
Өй эшләрендә булышыйк
Һәр көнне гадәт белән.

Кадерле әниләребез! Сезне бәйрәмегез белән котлап, сәламәтлек, озын гомер телибез. Гаиләгездә җылылык, өегездә нур, кадер-хөрмәтегез артсын. Сез җирдә иң газиз, иң якын кеше, чәнки җыр көйләп бишектә тибрәттең, беренче елмаюымны күреп куандың, туган телне өйрәттең, халык моңын күңелемә сеңдердең.

***“Мәктәп хәбәрчесе” редколлегиясе***



## Тәрбияви чаралар

Узган айда ил күләмендә "Психологик атна" игълан ителде. Безнең мәктәп тә әлеге чарага теләп кушылды. Атналыкны башлангыч сыйныф укучылары башлап җибәрде. Бу сыйныфларда "Әйдәгез дуслашыйк" диелгән уен-дәрес үткәрелде. Уеннар барышында балалар психологик сәламәтлекне саклауга һәм нығытуга, аралашудагы киртәләрне җиңүгә юнәлдерелгән күнекмәләр һәм алымнар белән таныштылар. Балаларның әлеге чарада бик теләп катнашуы, аларның актив булуларында чагылды. Шулай ук, урта сыйныф һәм зур сыйныф укучылары арасында "Әйдәгез дуслашыйк" дип аталган тренинглар үткәрелде.



"Яхшы эшләрең сине шатландырса һәм бозык эшләрең сине кайгыга салса, син чын кеше" (Хәдис). "Психологик атналыкны" дәвам итеп, башлангыч сыйныф укучылары арасында "Изгелек искермәс тә, тузмас та" дип аталган тәрбия сәгате уздырылды. Чара уен һәм әңгәмә рәвешендә барды. Укучылар изгелек, игелеклелек, мәрхәмәтлелеккә кагылган хәдисләр белән таныштылар.

Хокуклар – кешегә шәхес буларак яшәү һәм үсү өчен кирәк булган нормалар. Һәрбер кешенең яшәргә, ирекле һәм бәхетле булырга хокукы бар. Ә балаларның аерым, үзләренә генә хас хокуклары да була. 20 ноябрь – Бөтенроссия бала хокукларын яклау көне буларак билгеләнде. Бу уңайдан мәктәбебездә төрле чаралар үткәрелде. 1-4 сыйныф укучылары катнашында “Минем хокукларым һәм бурычларым” исемле әңгәмә оештырылды. Балалар хокук, бурыч сүзләренең мәгънәләренә төшенделәр, матур рәсемнәр ясадылар.



## Бөркетләргә әвереләдек

Мәктәбебездә башлангыч сыйныф укучыларын «Россия бөркетләре» сафына кабул итү чарасы узды. Тантана Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт гимннарын башкару белән башланды. Балалар «Бөркет»ләр турындагы риваять белән таныштылар. Ватанны яратырга, тырышып укырга, игелекле эшләр кылырга, үз сүзеңне тотарга, дуслыкның кадерен белергә, кайгыртучанлык күрсәтергә һәм вөҗдан буенча эш итәргә вәгъдә бирделәр. Укучыларга «Россия бөркете» символлы значоклар һәм рюкзаклар тапшырылды.

Бу тантаналы чара балалар өчен аеруча мөһим, чөнки ул Бөркетләр иленә ишек ача, анда аларны яңа, кызыклы һәм файдалы эшләр көтә. Укучылар хәзер гади укучы гына түгел, ә бердәм команда. Укучы үзе өчен генә түгел, ә сыйныфташлары өчен дә җавап бирә. бөркетләре үзара ярдәмләшүгә өйрәнәләр, игелекле эшләр эшлиләр, буш вакытларын файдалы үткәрәләр. Без аларны шушы вакыйга белән чын күңелдән котлыйбыз, Ватаныбыз традицияларенә тугрылыклы булып калуларын телибез.

## Юлларыбыз имин булсын!




21 нче ноябрьдә безнең мәктәптә "Юл һәлакәтендә һәлак булучыларны искә алу" көне үткәрелде. ЮИД хәрәкәте җитәкчесе Гафиятуллина Руфия апалары укучыларга әлеге бәйрәмнең асылын аңлатып, күңелсез очракларга юлыкмауның гади ысулларын искәртеп үтте. Шулай ук, соңгы 10 айда Татарстан Республикасы юлларындагы фаҗигаләр статистикасы белән таныштырды. Статистика буенча, быелның ун аенда гына да Россия юлларында 110 меңнән артык юл-транспорт һәлакәте булган, аларда 137 меңнән артык кеше җәрәхәтләр алган, 11,8 мең һәлак булган. Иң киң таралган хокук бозулар арасында – конкрет шартларга тизлекнең туры килмәве, юл чатларын үтү кагыйдәләрен бозу, каршы хәрәкәт полосасына чыгу һәм исерек килеш транспорт чарасы белән идарә итү. Автоаварияләрдә һәлак булучыларның күбесе - яшь кешеләр.

Укучыларыбызга бу дәресләр эзсез узмас. Гомерләренең озын булуын, фаҗигаләргә юлыкмауларын теләп калабыз. ***Гөлшат Закирова, башлангыч сыйныф укытучысы***





## Туган авылым

Минем туган авылым – иң яраткан урыным. Авылым кечкенә булса да, миңа ул зур күренә. Чөнки ул табигате белән бай. Авылыбызны кочагына алып, Чирмешән елгасы ага. Бу елга безгә – балаларга бигрәк тә күп рәхәтлекләр бирә. Язгы боз ташуларны карау да үзенә бер шатлыклы вакыйга. Чирмешәннең ярларыннан ташып агуы бик матур күренеш. Җәен без елгада су коенабыз, малайлар балык тота. Көзен каз-үрдәк шунда үзенә җим эзли. Кышын тагын да бу елга буе җанлана. Малайлар, кызлар тау шуалар. Кунаклар да елларда Чирмешән елгасын урап кайталар.

Авылыбызның һәйкәле булып Чирмешән ярында зур тупыл агачы үсә. Аны колачларга унлап бала кирәк, чөнки инде йөз яшьтән дә артыктыр. Аны берничә ел элек кондызлар ашый башлаган иде. Абыйлар тимер белән уратып саклап калдылар.

Авылыбызга ямь биреп манаралы мәчет тора. Анда бабайлар намазга җыела, ә балалар өчен гарәп язуына өйрәнү өчен түгәрәккә йөри. Балалар бакчасы да бик матур безнең. Аның ишегалдында төрле уен шартлары булганга, һәрвакыт балалар җыела. Шуның белән ул тагын да күңелле бакчага әверелә. Мәктәбем – минем иң яраткан урыным. Анда без берничә авылдан килгән балалар белән бергәләшеп укыйбыз. Укытучыларыбыз белем генә бирмичә, төрле кызыклы чаралар да үткәрәләр.

Авылымның һәр урамы матур һәм киң. Чисталыгы белән аерылып торган авылымда уңган халык яши. Һәркемнең йорты әллә кайдан балкып тора. Урамнар җәен яшеллеккә күмелеп утыра. Мин авылымны бик яратам.

***Настя Сафеева, VI сыйныф укучысы***

## Минем әни – иң әйбәте

Әни – бөтен кешенең яратып, назлап әйтә торган сүзе. Бу сүз әчендә нинди генә сыйфатлар юк. Ул назлы да, мәрхәмәтле дә, елмаючан да, тәмле пешерүче дә, сине яклаучы да. Төннәремдә аның якынлыгын белеп йоклавы да рәхәт. Ул синең көнеңне дә, төнеңне дә саклаучы. Әни, без йокыдан торган вакытка кайнар ризык әзерлисең, мәктәптән кайтуга тагын тәмле сыйларың белән каршылыйсың. Син мине һәрвакыт аңлыйсың, әни. Минем өчен бар нәрсәгә дә әзер син. Мин беләм, сиңа минем бөтен серем дә сыя, һәрвакыт аңлавыңа ышанам.

Синең куллардан бит гөлләр тама. Чөнки кулыңнан нинди генә эш килми. Рәсемнәрең синең – җанлы, чигүләрең – табигатнең нәкъ үзе! Укучылар да сине йомшаклыгың, аларга мең төрле кул эшләре өйрәтүең өчен ярата лар. Синең күңелең дә шундый матур. Шулай булмаса шундый матурлыклар тудыра алыр идеңмени?

Әни! Син – безнең, өч улыңның, иң кадерле кешесе. Әти өйдә күп вакыт булмаганда, безне тормышка да өйрәтәсең. Безнең белән бергә эшләп, хезмәткә өйрәтер өчен, күпме вакытыңны бирәсең.

Синең кадерне син авырып яткан вакытта тагын да күбрәк аңладым. Синең беркайчан да авырмавыңны телим. Кояш гомере телим мин ,әнием, сиңа, дип җырлыйлар бит. Мин дә шул җырга кушылам.

***Айназ Хәйруллин, IX сыйныф укучысы***





## Республикакүләм шахмат турниры

16-19 ноябрь көннәрендә шахмат буенча Татарстан Республикасының команда чемпионаты булып үтте. Әлеге чара Республиканың шахмат буенча спорт мәктәбендә уздырылды. Турнирда Казан, Яр Чаллы, Яшел Үзән, Лениногорск, Чистай, Бөгелмә, Кукмара, Баулы, Актаныш, Мамадыш, Буа, Балтач, Саба, Аксубай һәм Питрәч районнарыннан 39 команда катнашты. Аксубай командасы составында безнең мәктәпнең VII сыйныф укучысы **Гафиятуллин Фаил** төп уенчыларның берсе булды. Бәйгенең һәр 7 туры да бик кызу үтте. 4 өстәлдән дә көчле уен нәтиҗәсе таләп ителде. Турнир нәтиҗәләре буенча, 35 меңнән азрак кеше яшәгән районнар арасында урыннар түбәндәгечә бүленде: 1 урын – Актаныш районы, 2 урын – Аксубай районы, 3 урын – Саба районы командалары алды. Командалар кубок, грамота, медальләр, акчалата приз белән бүләкләнде.




## Чирмешәндә көрәш бәйгесе

4 ноябрь көнне Чирмешән районы үзәгендә Россия чемпионы Галимов Ильяс Самат улы истәлегенә багышланган билбау көрәше булып узды. Яшь көрәшчебез **Җамалетдинов Зөлфәт** үз авырлыгында (28кг) III урынны яулап кайтты. Аңа алдагы бәйгеләрендә уңышлар теләп калабыз.